

# ЧИШМӘ БАШЫ

2024 гаилә елы

НОЯБРЬ 2024 ЕЛ

*Татарстан Республикасы*
*Арча муниципаль районының*
*«Арча 8нче балалар бакчасы»*
*муниципаль бюджет*
*мәктәпкәчә белем бирү*
*учреждениесе*

Бу санда:

- «Йөрәк жылым сиңа, әнием...»
- Бәйрәм белән әниләр!
- Әти-әни белән уйнау күнелле

Ата –аналар һәм балалар өчен мәгълумати-танып белү

## 24 ноябрь – Әниләр көне!



## Әнием –иң кадерлем.

*Әниләр кебек кадерле*
*Бер кеше юк бу җирдә.*
*Гел яратып торыр идем,*
*Аерылмас идем бер дә.*
*Һәр көн иртән әниебез*
*Бармасын иде эшкә.*
*Көне буе эшләп арып*
*Кайтмасын иде кичкә.*
*Безнең янда әниебез*
*Уйнасын иде көн дә.*
*Әнием кайчан килә?- дип*
*Еламас идем мин дә*
*Әниләрен сагына шул,*
*Бездәй нәни балалалар.*
*-Тизрәк кил!-дип бакчаларда*
*Куллар болгап калалар.*

*Диля Абдуллина*

Фотода: Гафутдинов Ислам уртанчы төркеменнән, онлайн үткән конкурсында “Әни һәм мин милли киемендә” дигән номинациясендә 1 нче урын яулаучы.

# «Йөрәк җылым сиңа, әнием...










Әни... якты кояшка тиң, иң кдерле кеше. Дөньяда бәлки шулкадәр якын, ягымлы, ярдәмче кеше юктыр. Кеше кайда гына булса да, ни эшләсә дә, иң кирәк урын – әни янында, туган йортта. Ничә яшьтә булса да, һәркем үкереп елаган вакытта әнинең юатучы йомшак кулларын хәтерли. Башны сыйпап, бишек җырларын көләүче, кайгы-шатлыкларны уртаклашучы, гомер таянычы ул әни. Ул һәрберебез өчен иң кадерле, иң яхшы, иң матуры, гомумән, тормышта иң әһәмиятле кеше. “Әни, әнием, әнкәй” - дип назлап әйтәбез дә, күңелебездәге бөтен хис-кичерешләребезне шул гади сүзгә салабыз. Ә бит шушы өч хәрефтән торган сүзне күпме наз, җылылык һәм күңел тойгысы белән әйтәбез!

Хатын-кызның иң югары бурычы – әни булудыр, чөнки “әни” - бала әйткән беренче сүз. Бу сүз дөньяның күпчелек телләрендә бер үк төрле яңгырый һәм дөньяда иң якын, иң яраткан кешене атый.

Нәкъ менә шул сыйфатлар җәмгыятькә әниләр көнен игълан итәргә сәбәп булгандыр. Россия Ф Президентының 1998 елның 30 гыйнварында чыккан 120 номерлы карары нигезендә, илебездә ноябрь аеның сонгы якшәмбесе ел саен “Әниләр көне” булып билгеләп үтелә. Быел ул 24 ноябрь көненә туры килде.

Илебездә билгеләп үтелә торган күпсанлы бәйрәмнәр арасында әниләр көне аерым урын алып тора. Бәйрәмнең максаты – хатын-кызга сакчыл караш традицияләрен хуплау, гаилә нигезләрен ныгыту, безнең тормышта төп кешенең – әнинең әһәмиятен аеруча билгеләп үтү. Бу бәйрәм беркемне дә битараф калдыра алмый. Нәкъ әниләр көнендә үз балаларына мәхәббәт, игелек, наз бүләк итүче барлык аналарга рәхмәт сүзләре әйтәсе килә. Тик нинди генә җылы сүзләр әйтмәсәк тә, җитмәс төсле... Әниләр көне – искиткеч көн. Безнең һәрберебез әниебезне искә төшерергә, аңа шалтыра-тырга, бәлки янына кайтып, аны котларга, аның сәламәтлеге һәм кәефе ничек булуы белән кызыксынырга тиешле көн!

Мөлаем һәм ягымлы кузле, акыллы, сабыр һәм түземле, шәфкатьле, авыр вакытларда арканы сыйпаучы кадерле куллы, боз эретерлек җылы сүзле, бала өчен кайгырып, төннәрен күз йоммаучы әниләребез, сезне бәйрәмегез белән чын йөрәктән котлыйбыз. Сезгә ныклы сәламәтлек, озын гомер, рухи көч, тормыш зирәклеге, сабырлык, бәхет, гаилә уңайлыгы телибез. Безгә биргән чиксез мәхәббәтегез, назыгыз һәм кайгыртуыгыз өчен рәхмәт!










Бакчабыздагы барлык төркемнәрдә балалар әниләренә бүләкләр ясады һәм әниләргә багышлап кичәләр узды.

# ӘТИ-ӘНИ БЕЛӘН УЙНАУ КҮҢЕЛЛЕ!


















Газетаны чыгару буенча җаваплы татар теленә өйрәтү буенча тәрбияче: Кәримова Гүзәл Рафаил кызы